Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының
Клементейкино авылы Советы

# КАРАР

21 январь 2022 ел

№ 31

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Клементейкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча Әлмәт районы Советы тәкъдимен кабул итү турында» 2021 елның 14 октябрендәге 23 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, «Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзү тәртибе хакында» Әлмәт муниципаль районының 2015 елның 6 маендагы 468 номерлы карары нигезендә

Клементейкино авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Клементейкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча Әлмәт районы Советы тәкъдимен кабул итү турында» 2021 елның 14 октябрендәге 23 номерлы карарына (алга таба- карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 карарның 1 пунктында «үзгәрешләр кертү өлешендә» сүзләреннән соң «(әзерләү һәм эшләү)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Клементейкино авылы, Центральная урамы, 38А йорт; Багряж авылы, Кызыл Йолдыз урамы, 38А йорт; Яңа Чишмә авылы, Гафиятуллин урамы, 3А йорт торак пункт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Клементейкино авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Клементейкино авыл
җирлеге башлыгы Л.Э. Языков